| | |
|---|---|
| СОВЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

2019 ел, 15 июнь　　　　Кече Мәми авылы　　　　№11

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Кече Мәми авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә узгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131- ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы Федераль законның 15 нче статьясына үзгәреш кертү хакында»гы 2017 елның 29 нчы декабрендәге 477-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Советының 2017 елнын 3 нче апрелендәге «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 98.10 пунктты белән тулыландырырга:

«98.10. Транспорт чараларының һәр тукталышында, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары янында (торак, җәмәгать һәм җитештерү бинаалары, төзелмәләр һәм корылмалар, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан йортларны да кертеп) ял итү урыннарында I,II төркем инвалидлары белән идарә ителә торган транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен, шулай ук III төркем инвалидларына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм мондый инвалидлар яки инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларына урыннарнын 10 проценттан да ким булмаган өлеше (кимендә 1 урын) булеп бирелә. Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» билгесе

келырга тиеш. Индивидуаль файдалану өчен «Инвалид» тану билгесен бирү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләте биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. Парковкалар өчен курсәтелгән урыннарны башка транспорт чаралары алырга тиеш тугел».

2. Элеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» тубәндүге адрес буенча (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенен рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Кече Мәми авыл
җирлеге башлыгы Е.Н.Алексеева